# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан авылы торак пунктында 2025 елда гражданнардан үзара салым кертү турында

2024 елның 05 декабреннән № 5

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең Түбән Ослан торак пункты Красноармейская урамы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 5500 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
урамнарны яктыртуны җайлау.

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Түбән Ослан авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче,
Югары Ослан муниципаль районының
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А.В.Архиреев